**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ ВЕРХНЕКАМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
улица Дружба, дом 1а, село Верхняя Каменка, 423108

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**ЮГАРЫ КӘМИНКӘ АВЫЛ СОВЕТЫ**
Дружба урамы, 1а йорт, Югары Кәминкә авылы, 423108

тел./факс (84396) 2-31-60/2-34-16 email: Vkam.Cmn2@tatar.ru

№ 109 07 февраль 2019 ел

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 мартындагы 78 номерлы «Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районының Югары Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында», 2018 елның 20 октябрендәге 382-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», 2018 елның 27 декабрендәге № 559-ФЗ «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законнар, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Югары Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Югары Кәминкә авыл җирлеге Советының 2018 елның 12 мартындагы 78 номерлы (авыл җирлеге Советының 2018 елның 3 маендагы 82 номерлы, 2018 елның 24 августындагы 91 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Карары белән расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Югары Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 3 өлеш «Муниципаль хезмәткәрнең хокукый хәле (статусы)» түбәндәге эчтәлекле пунктчалар белән тулыландырырга:

- «3.4.3. Граждан муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасында билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәрнең муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы, тиешле муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлык яки үзлекләре (ата-аналар, ир белән хатын, балалары, абыйлы-энеле, сеңелләре, шулай ук ир белән хатынның абыйлары, апалары, ата-аналары, балалары һәм балаларның ире яки хатыны) булган очракта, муниципаль берәмлек контроль-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларын били алмый»;

- «3.4.5. Җитәкче булып торучы муниципаль хезмәткәр җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын төшереп калдыру максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмый».

- 3.6.1. пунктчаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«- эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш) катнашырга;

- һөнәр берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу;

- съездда (конференциядә) яки башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында катнашулар;

- күрсәтелгән коммерциягә карамаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән сәяси партиядән һәм һөнәри берлек органыннан, шул исәптән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) ялгызак башкарма орган буларак яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына, муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртиптә алынган яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән керү, гамәлгә куючысы (акционер, анда катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтүдән тыш, оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыруны яисә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталында катнашу өлешләре) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә;

- федераль законнарда каралган башка очракларда».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән

муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуда җаваплылыкны үз өстемә алам.

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Югары Кәминкә авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе К.М.Гыйләҗев**